Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Советы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге Башлыгы
КАРАРЫ

25 октябрь, 2023 ел № 5

Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге торак пунктларында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06.10.131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 һәм 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге уставының 22 статьясы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Надеждино авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының 2019 елның 08 ноябрендәге 139 номерлы (2021 елның 13 декабрендәге 33 номерлы карары белән расланган үзгәрешләр белән) Надеждино авыл җирлеге Советы карары нигезендә карар бирәм:

1. Надеждино авыл җирлегендә түбәндәге торак пунктларда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыеннарын билгеләргә:

1.1. Надеждино авылында. Гражданнар җыенын 2023 елның 10 ноябрендә 14.00 сәгатьтә Мәктәп урамы, 4 нче йорт адресы буенча урнашкан авыл мәдәният йорты Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез, 2024 елда Надеждино торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә, 1 группа инвалидларны, эшләмәүче 2 группа инвалидларны, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарын, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларны, биш һәм аннан да күбрәк балалары булган күп балалы гаиләләрне, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын бер тапкыр бирелә торган түләүләрдән (үзара салымнан) азат итеп, һәм җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны алдагы эшләрне башкару өчен тотылу белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.2. Аркатау авылында. 2023 елның 11 ноябрендә 11.00 сәгатьтә 1 Май урамындагы Чиркәү янында гражданнар җыенын үткәрергә:

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Аркатау торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш һәр кешедән 3000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- Аркатау авылы Новатор урамындагы юлга вак таш түшәү

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.3. Урта Ия авылында. 2023 елның 11 ноябрендә 11.00 сәгатьтә минутта Комаров урамы буенча 13 номерлы йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Урта Ия торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл урамы юлларын ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

1.4. Петрово авылында. 2023 елның 11 ноябрендә 14.00 сәгатьтә минутта Кибет урамы буенча 5 номерлы йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда Петрово торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 5000 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен куллану белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау

«РИЗА» «КАРШЫ».

2. Әлеге карарны «Вперед» («Алга») газетасында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Надеждино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

Питрәч муниципаль районы
Надеждино авыл җирлеге башлыгы И.З. Галәветдинов